Балалар журналы

ISSN 0868-4545



Ләбиб Лерон

Язгы әкият

Яз иде. Күк йөзендә алсу кебек елмайган гүзәл бер көн иде.



сеңелесе Ләйләгә:

— Ләйлә, әйдә, урманга җыярга барабыз, — диде. — Әниебезгә бүләк итәрбез!



шундук риза булды. Алар янында белән бөтерелә иде.

— Мин дә сезнең белән барыйм әле, — диде .

— Минем дә барасым килә, — диде .

— Әйдәгез, киттек! — диделәр .

бакчасы аша киттеләр болар. Алдан койрыгын болгый-болгый бара, аның артыннан элдерә, алардан калышмаска тырышып, кызу-кызу атлыйлар. Юлда боларга матур очрады.

— Мине дә ияртегез әле, — диде .

Ияртәләр, янә киттеләр. Ниһаять, бакчасы артына килеп җиттеләр.

Бакча артында зур үсеп утыра иде. Аны иң элек күреп алды. Аннары бүтәннәр дә күрделәр.

— Нинди матур урман! — диде әлеге тирәли әйләнә-әйләнә.

— Искиткеч! — дип сокланды . Мондый урманда минем беренче мәртәбә булуым әле.

— күптер инде монда! — диде җирдән эзли-эзли.

— Кочакка сыйган кадәр күтәрәбез, — диде . Һәммәсе тирәсеннән эзләргә

© "Салават күпере", 1999 ел

кереште. Әмма ни , ни , ни , ни , ни генә тә тапмады.

Шулвакыт башыннан тавышы ишетелде.

— агачлык урман була димени! — диде әлеге . — Беләсегез килсә, безнең авыл тирәсендә нинди урман да юк! Әрәмәлек бар-барын да, ул да ерак! Сезнең әллә берегезнең дә урман күргәне юк идеме моңарчы?

— Юк шул. Без әле кечкенәләр бит. Миңа 3 кенә яшь, — диде .

— Миңа 2 яшь тула, — диде .

— Миңа 1 яшь инде, — диде .

— Миңа да, — диде .

— Мин үземә ничә яшь икәнен белмим. Санарга өйрәнмәдем әле, — дип чикылдады .

— Аңлашылды, — дип каркылдап алды . — Ярый, алайса, мин Җил дустыма әйтим әле, ул хәзер сезгә бәйләме китерер.

шулай диюгә, , да, дә кочагында бәйләме пәйда булды. Җил белән дә, хәтта да онытмаган. Миңа да 1 бөртек бирде әле.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Бәрәч!

Журналыбызның баш рәссамы Фәрит Муллахмәткә дә илле яшь тулган икән! Гаҗәпләнмәслек тә түгел шул. «Салават күпере» журналханәсендә эшли башлаганда шундый яшь-яшь иде ул, хәзер дә шулай. Аңа илле яшь тулган булуына ышанасы да килми хәтта. Хәер, аз гына ышанырга да була, чөнки Фәрит абыегызның бик матур оныгы бар бит инде.

Без, журналханә хезмәткәрләре, Фәрит абыегыз Муллахмәтне синең исемнән дә туган көне белән - юбилее белән! - чын күңелдән котлыйбыз, янәдән-янә матур рәсемнәр белән безне сөендереп торуын телибез.

Нәҗибә апагыз Сафина — Башкортостан төбәгеннән. Хәзерге вакытта Казанда яши һәм иҗат итә. Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә шигырьләр яза. Ул һәрвакыт көләч, сөйләшкәндә шаян сүзләр генә әйтеп сөйләшә. Бу язның беренче аенда Нәҗибә апагыз аеруча шат йөри. Шат йөрмәслек тә түгел шул! Мартта аның туган көне. Туган көннең дә нindие әле! Юбилей дип аталганы. Әйдәгез, Нәҗибә апагызны олуг бәйрәме белән котлыйк, аңа саулык-сәламәтлек, иҗат уңышлары телик!

Нәҗибә Сафина

Мәче белән бөҗәк

Йомшак басып
мәче бара.
Бөҗәк — кызыл,
мәче — кара.

Мәче дәшә
бөҗәккә:
— Кара әле
бу якка!
Тыңла минем
сүземне! —
Һәлак итмә
үзеңне!
Пыяла
бик тә шома —
Егылма,
димен шуңа.

Тыңламады
шул бөҗәк, —
Чак ярылмады
йөрәк.



Рәссам Светлана Привина

Шарт итеп
куйды аяк.
Каян алырга
таяк?

Мәче — кара,
күңеле — ак.
Бөҗәкне җәлли
шул чак:
Бәйләп куя
аягын,
таяндыра
таягын.

Елаудан
туктый бөҗәк.
Мәчегә
суза чәчәк.

Мәче — кара,
күңеле — ак:
Дуслар белән
яхшырак!




Нәни дус! *Менә синең алда ике открытка. Әлбәттә, алар чын открыткалар түгел. Аларны элемтә бүлеге аша җибәреп булмый. Әмма син ул открыткаларны һәйбәтләп кисеп алып, әти-әниеңә, әби-бабаңа, абый-апаңа, дусларыңа бәйрәм белән котлап, матур-матур сүзләр язып яисә рәсемнәр ясап бүләк итә аласың.*





Сәләвәт күпере



Кемгә

Кемнән

Рәссам Светлана Привина



Сәләвәт күпере



Кемгә

Кемнән

Кадерле укучыбыз!
Шушындый китапчыкларны үзеңдә әледән-әле булдырасың килсә, матур-матур әкиятләр, шигырьләр, такмак-такмазалар укырга яратсаң, «Салават күпере» журналын өегезгә алдырырга онытма. Бу хакта өлкәннәрнең исенә төшер.

Рәссам Илдар Нәфиев


Дускай!

Журналның урта битен ипләп кенә алып, кара сызыклар буенча кис, сары сызыклар буенча бөклә дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җый. Булгач-булгач чын китап булсын - уртасын ике урыннан төпләп тә куй.



©«Салават күпере« китапханәсе.

Рәшит Ягъфәр



Эшләпә

Ни хикмәтле эшләпә бу,
Эшләпә ни эшләтә?
Кидергән идем бозауга —
Айгыр кебек кешнәтә.

Юрга

Кара юрга чыкты юлга,
Юргалап китте юлда.
Әтәчебез иргып чыкты —
Юргаламакчы ул да.

Яшен

Я, яшеннән кем курыксын?!
Яшьнәсен, әйдә, «чарт-чорт».
Юрган астына керәм дә,
Каранып ятам ялт-йолт.

Әптчи

Әптчи, әптчи,
Әнә килә карт песи.
Карт песинең йоны юк,
Бу малайның юне юк.



Кадерле нәни дус!

Бу «Әкәмәт әлифба»ны синең өчен, әти-әниең һәм тәрбиячеләр өчен фольклорчы-галим, язучы Рәшит Ягъфәр махсус иҗат иткән. Телең ачылган вакытта һәм, үсә-үсә, авазларны дөрес әйтергә өйрәнгән чакта әлеге кызыклы әлифбаның сиңа ярдәме тими калмас.

Шигъри такмакларны кызыксынып, игътибар белән укы, өйрән, әти-әниеңә, әне-сеңелеңә яисә абый-апаңа сөйлә. Уңышлар сиңа, дәү үс!

Ләбиб Лерон

Өрмә этем

Өрмә, этем, өрмә, этем, —
Өрә белми өрәсең.
Беләсең бит тәм-том төяп,
Әти кайтып керәсен.

Үпкә

Үпкәң булса, үпкәләмә —
«Үпкә бирик» диярләр.
Үпкәләгәнне төярләр,
Үткеннәрне сөярләр.

Җәмил һәм җәй

Җир җиләкләре җыярга,
Җиләкле җәйләр җитәр.
Тик Җәмил чебеннән курка,
Чебен тисә, «чер» итәр.

Һавалы һавия

Һавия бигрәк һавалы,
Һаваланмау сирәктер.
«Һавалану» дигән чирдән
Дәвалану кирәктер.

Ләкләк

Ләкләк ләмдә батмый, дип
Ләмгә баскан Ламига.
Ярый тартып чыгарырга
Ләкләк булган янында.

Маймыл

«Маймыл, нигә син маймыл?» — дип,
Мин сорадым маймылдан.
Әйтте: «Маймыл булмас идем,
Акыл ягы сай булган».

Нигъмәт

Нигъмәткә нәрсә кирәк,
Нигъмәткә нигъмәт кирәк.
Нигъмәт кебек нигъмәт сөйгән
Бу дөньяда бик сирәк.

Ондатра

Ондатра, ондарта
Анда тора мыни ул?
Ондатра суда тора,
Монда торамыни ул.



«Ялкын» журналханәсендә озак еллар баш мөхәррир булып эшләгән хөрмәтле язучыбыз Роза апа Хафизовага ошбу 1999 елның 6 февралендә 70 яшь тулды. Без Аны олуг бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз һәм Аңа саулык-сәламәтлек телибез.

Рәссам Фәрит Муллахмәт

Кадерле дускай!

Журналның урта битен иплəп кенә алып, кара сызыклар буенча кис, сары сызыклар буенча бөклә дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җый. Булгач-булгач чын китап булсын - уртасын ике урыннан төпләп тә куй.

©«Салават күпере« китапханәсе.




Күгәрчен

Чыпчыкларга ярма сиптем,
Очты, төште күгәрчен.
Күгәрчен, күгәрчен,
Ачыккансың күрәмсең.

Тып-тып итеп ярма чүпли
Кызыл тәпи күгәрчен.
Күгәрчен , күгәрчен,
Бигрәк матур икәнсең.

Ашап туйгач, рәхмәт әйтеп,
Очты-китте күгәрчен.
Күгәрчен, күгәрчен,
Сау бул, сау бул, күгәрчен.





И сабыем! Җаный күзеләре
Җиһанның изге нуры!

Роза Хафизова

Тукран

Тукы, тукы, тукран
Аккаенга утырган.
Ялтыравыклы чапаны
Каурыйданмы тукылган.

Тукы, тукы, тукран
Аккаенга утырган.
Тукы, тукы, тукылдый да
Туктап тыңлый тукран.

Тукы, тукы, тукылдый да
Аккаенга утырган.
Яратканын тукы, тукы,
Чакырадыр тукран.


Әпипәгә биибез

Без, без, без идек лә,
Алты матур кыз идек.
Чиккән читекләр кидек тә,
Сезгә биергә килдек.

Кил, кил, килегез лә,
Дәртле бию күебез.
Читек-кәвеш киегез дә,
Безнең белән биегез.

Бер, ике, өчегез,
Иң яхшы биючегез,
Әзерләнсен, чыксын түргә —
Әпипәгә биибез.





Кояшка салкын тигән

Гөлназ бүген өйдә тора,
Бакчасына бармаган.
Салкын тигән. Тышта буран,
Җирне ак кар каплаган.

Курчагы Алсу кулында,
Гөлназ аны юата,
Әкият сөйләп, көйли-көйли,
Үзе белән йоклата.

— Йокла, йокла, — ди, — курчагым,
Күрәмсең, тышта буран.
Кыш бабай килгән ич безгә,
Сакалы ап-ак кардан.

Кояш юк күктә, караңгы,
Күк соры күлмәк кигән.
Кар ашагандыр, мөгаен, —
Кояшка салкын тигән.

Курчагы бигрәк акыллы,
Тыңлап Гөлназның сүзен,
Тыныч йоклый мендәрендә
Йоммыйча ике күзен.

Тискәре

Минем нәни энем бар,
Күр, игътибар ит әле.
Үзе шундый тискәре,
Искәйләрең китмәле.

Мин тискәре түгел ич,
Ул кемгә соң охшаган!
Сөйләшә дә белми үзе,
Үртәшә үк башлаган.

Ачулансаң — үпкәли,
Мине һич тә тыңламый.
Апа дип тә уйламый,
Әйткәнемне аңламый.

Бик яраткач энемне,
Миңа кала түзәсе.
Бәлки үскәч төзәлер —
Бар бит әле үсәсе.




Безнең авыл

Чырык-чырык чыркылдаша
Чыпчыклар талда.
Челтер-челтер чишмә ага
Чияле тауда.

Шаярыша, уйный йөзә,
Балыклар күлдә.
Ап-ак шомырт чәчәкләре
Тибрәлә җилдә.

Шундый матур безнең авыл —
Тиңе юк җирдә.
Яшибез татар илендә,
Иң матур илдә.





Җитәкләшеп уйныйбыз

Җитәкләшеп, тезелешеп,
Әйлән-бәйлән уйныйбыз.
Биибез дә, җырлыйбыз да,
Ялындырып тормыйбыз.

Җитәкләшеп, тезелешеп,
Түгәрәк уйнаганда,
Бик күңелле була безгә
Бергәләп җырлаганда.

Җитәкләшеп, тезелешеп,
Уйнарга без бик оста.
Бигрәк матур җырлыйбыз,
Әниләр карап торса.



Алсу алма

Айнур алсу алманы
«Алмыйм,» — диеп алдады.
Алсу алма биргән идем,
Кабыгы да калмады.

Бытбылдык

Болында бер бытбылдык
«Быт-быт» диеп бытбылдый.
Тотып алыйм дигән идем,
«Тот!» диде дә, юк булды.

Вафа

Әй, Вафа, Вафа, Вафа,
Көн дә уенчык вата.
Уенчыгым ватылды, дип,
Акырып елап ята.

Гөлдери күгәрченем

Гөрнәчәдә күгәрченем
Гөлдери дә гөлдери.
Гөрнәчәдә гөлдерәмә,
Күгәрченем, кил бире.

Футляр

Фанай, Фаный, Фәнзаман,
Футляр тапкан бер заман.
«Әйбернең үзе кирәк!» дип,
Елап ята, ди, һаман.

Халик һәм балык

Хахылдап көлә Халик:
Балык тота бар халык.
Балыкларны үстерә ул,
Күлгә шикәр-бал салып.

Чи чия

Чи чияне чәйни-чәйни
Чигәң ник чатнап чыкты?
Чи чия биреп алдыйлар
Синең күк мактанчыкны!

Шымытыр

Шамил әйтте: шаулама син,
Тик утыр, бик шым утыр.
Шуның өчен бирәм сиңа
Бик матур бер шымытыр.



Давыт белән Данияр

Давыт белән Даниялның
Дөньяга китте даны.
Сугышалар да, бергәләп
Юалар борын канын.

Елкы

Елтыр-елтыр елтырыйдыр
Мут егетнең елкысы.
Елкысыннан егылып төшкән,
Елый, адәм көлкесе.

Илдарларда

Илдарларга килеп керсәм,
Имәнеп киттем нигә?
Бәтиләрен тибеп егып,
Кәҗәне сарык имә.

Кара карга

Кара, кара, карганың
Канатлары кап-кара.
Ышанмасаң: «Ник кара?» — дип
Үзеннән барып сора.



Пәри

Пәри, пәри, пәрәмәч,
Пәри чәчен тарамас.
Пәри кебек бер дустым бар,
Битен юмый ярамас.



Рәфис, Рәмис, Рәшит...

Рәфис, Рәмис, Рәшит,
Әйдә, бергә берләшик.
Әйдә, бергә сүз берләшеп,
Черки белән көрәшик!

Сыерыбыз

Сыерга салам салганда
Сынды сәнәк саплары.
Сыерыбызның гармун уйнап,
Җырлап йөргән чаклары.

Талип

Траттата, траттата,
Талип «сафсата» сата.
Талип дустым, әйтмәсеңме:
Күпме тора «сафсата»?

Уф-алла

Уф-алла, уф-алла,
«Уф» димим юкка-барга:
Җәйнең эссе көннәрендә
Батып ятам ак карга.



	Апрель	Май	Июнь
Дүшәмбе	5 12 19 26	3 10 17 24 31	7 14 21 28
Сишәмбе	6 13 20 27	4 11 18 25	1 8 15 22 29
Чәршәмбе	7 14 21 28	5 12 19 26	2 5 16 23 30
Пәнҗешәмбе	1 8 15 22 29	6 13 20 27	3 6 17 24
Җомга	2 9 16 23 30	7 14 21 28	4 7 18 25
Шимбә	3 10 17 24	1 8 15 22 29	5 8 19 26
Якшәмбе	4 11 18 25	2 9 16 23 30	6 9 20 27



Әнвәр — минем оныгым.
Аңа 6 яшь.
Ул беренче рәсемен
4 яшендә чагында ясады.
Әнвәр моңлы бала да —
җырларга бик ярата ул.
Мин оныгыма уңышлар,
матур киләчәк телим.

Әхмәт ГАДЕЛ



Әнвәр Димиев-Гаязов рәсемнәре


(Казан).








Бу ике рәсемгә игътибар белән кара әле. Аларның берсендә бер Бахбай, өч Коңгызбай һәм бер Чикылбай дигән тычканнан тыш Мыраубай исемле бер песи дә бар. Кайда икән ул? Мыраубайны һәм рәсемнәрдә булган аерымлыкларны тап әле, дускай.



Рәссам Максим ПОКАЛЕВ





Конкурс!
Конкурс!
Конкурс!


Мин бит бу?!

Хөрмәтле өлкәннәр!
Без Сезнең өчен иң кадерле, иң асыл затларның – сабыйларыгызның сурәтләрен бастыра башлыйбыз.
Ул сурәтләрне Сез җибәрәсе була инде.




Шартлар: сурәткә караган кеше йә **гаҗәпләнерлек**, йә **сокланырлык**, йә **көләрлек**, һичьюгы, **елмаерлык**, ә сабый журналда үзен күргәч: **«Мин бит бу?!»** – дип сөенерлек булсын.

Иң кызыклы фоторәсем һәм комментарий авторларын, әлбәттә, бүләкләр көтә. Тик, зинһар, баланың исемен, яшен, яшәгән урыныгызны күрсәтергә онытмагыз.




Бәхтияр (3,7 яшь):

– Вилсәпидемә атланып,
Сурәткә төштем мактанып...



Фәридә (2 яшь):

– Кайда гына утырсам да
Кулдан «Әлифба»м төшми...



— Бакчага барыйм микән,
Әллә соң бармыйм микән?..



— Атым матур, мин гүзәл —
Күзләр тимәсен безгә!..

Салават күпере

3(109) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ 1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 4 битендә
Светлана ПРИВИНА рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 15.2.99 ел.
Басарга кул куелды 15.2.99 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Басма табак 1,5 (2,1).
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 17162 данә. Заказ 3-111.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Такмаклар

Халык авызы иҗаты
(Җыючы Г. Зәйнәшева)
Г. Беляева көе

Ике тавык бакча казый
Итәкләрен кыстырып.
Әтәч агай трубка тарта
Күләгәгә утырып.

Безнең песи бигрәк уңган —
Комганга су тутыра.
Бозавыбыз мич башында
Оек белән утыра.

Иртән торып тышка чыксам,
Тараканнар кар көри.
Чикерткәләр туфли киеп
Урамда биеп йөри.

Без җырладык шаян җырлар,
Без җырладык арганчы.
Хәзер безгә кул чабыгыз
Учыгыз кабарганчы.







